ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 3 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 25 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“25 статья. **Җирләрне саклау максатлары һәм асылы**

1. Җирләрне саклауның максатлары җирләрнең һәм туфракның пычрануын, ярлылануын, начарлануын, бозылуын, юк ителүен һәм җирләргә, туфракка башка тискәре йогынтыны булдырмый калудан һәм бетерүдән, шулай ук җирләрдән рациональ файдалануны, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә туфракның уңдырышлылыгын торгызу һәм җирләрне яхшырту өчен, тәэмин итүдән гыйбарәт.

2. Җирләрне саклау дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, юридик һәм физик затларның әйләнә-тирә мохитнең мөһим компоненты һәм табигать ресурсы буларак җирне саклауга юнәлдерелгән эшчәнлегеннән гыйбарәт.

3. Җирләрне саклау максатларында җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр һәм җир кишәрлекләрен арендалаучылар түбәндәге чараларны үткәрергә тиеш:

1) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын яңадан торгызу;

2) җирләрне су һәм җил эрозиясеннән, ташкыннардан, су басудан, сазлыкланудан, икенчел тозланудан, кибеп корудан, катудан, химик матдәләр, шул исәптән радиоактив, башка матдәләр һәм микроорганизмнар белән пычранудан, җитештерү һәм куллану калдыклары белән пычранудан һәм башка тискәре йогынтыдан саклау;

3) авыл хуҗалыгының уңдырышлы җирләрен агачлар һәм куаклар, чүп үләннәре басып китүдән саклау, мелиорациянең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу.

4. Җирләрне саклау чаралары федераль законнар нигезендә үткәрелә.";

2) 28 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"28 статья. **Химик матдәләр, шул исәптән радиоактив, башка матдәләр һәм микроорганизмнар белән пычрануга дучар ителгән җирләрдән һәм җир кишәрлекләреннән файдалану**

Химик матдәләр, шул исәптән радиоактив, башка матдәләр һәм микроорганизмнар белән пычрануга дучар ителгән җирләр һәм җир кишәрлекләре, шулай ук аларда урнашкан биналар, корылмалар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә файдаланылалар. Мондый җирләрдә һәм җир кишәрлекләрендә авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм реализацияләү тыела.";

3) 44 статьяның 2 пунктында "мондый җир кишәрлегеннән тиешенчә файдалану шарты белән" сүзләрен "мондый җир кишәрлегеннән файдаланганда җир кишәрлекләрен бирүгә вәкаләтле дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында, җирле үзидарә органнарында дәүләт җир күзәтчелеге кысаларында ачыкланган һәм бетерелмәгән Россия Федерациясе законнарын бозулар хакында мәгълүмат булмау шарты белән" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2016 елның 19 ноябре
№ 90-ТРЗ